**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

утыз бишенче утырыш
**КАРАРЫ**

29 нчы октябрь 2024 ел **№ 270** Теләче ав.проект

Теләче муниципаль район Советының 2018 елның 12 апрелендәге 124 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы карары нигезендә Теләче муниципаль районы Советы **карар итте**:

1. Теләче муниципаль район Советының 2018 елның 12 апрелендәге 124 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» карарына (24.08.2018 № 136, 20.11.2019 № 209, 09.10.2020 № 9, 12.11.2021 № 86, 27.12.2021 № 103, 29.04.2022 № 125, 08.09.2022 № 142, 03.11.2022 № 151, 03.05.2024 № 244 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 13 990 сум күләмендә расларга.».

1.2. Карарның 2 номерлы кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Теләче
муниципаль районы Советы карарына
2 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның айлык акчалата хезмәт хакы күләме

| Вазыйфа исемнәре | Коэффициентлар |
|---|---|
| | 8 төркем |
| 1 | 2 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы | 37 036 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары | 33 333 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 33 333 |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы башлыгы А.Г. Фәтхуллин